**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**3 нче октябрь 2016 ел** **№ 77**

Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

12.06.2002 Федераль законның 15 статьясы нигезендә № 67-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында", "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы "Күгеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы," Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 30 сентябрендәге 33 номерлы «Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында»гы карары, Бишнә авыл җирлеге Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 76 номерлы "Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында» гы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. 2016 елның 20 ноябренә Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2017 елда Бишнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

1. 1. урам утларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту;
2. ирекле янгын сагы һәм махсус техниканы карап тоту, шул исәптән ягулык-майлау материаллары сатып алу,
3. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт( авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**